ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел, « 01 » апрель** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль Закон, 2007 елның 18 маендагы 196 нчы номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль Законны тормышка ашыру буенча чаралар турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 нче номерлы «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы Россия Федерациясе карары нигезендә Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче Кушымта һәм 2 нче Кушымта буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2019 елның 1 апреленнән 5946 сум 47 тиен дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Кырлай авыл җирлеге Башлыгы Сиражетдинов Ф.Г.

Арча муниципаль районы
Иске Кырлай
авыл җирлеге башкарма комитетының
2019 елның «01» апрельдә кабул
ителгән 5 номерлы Карарына
1 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү һәм китерү | 3937-43 |
| 3. Мәетне (калдыкларын) зиратка алып бару | 475-51 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1533-53 |
| **Барысы** | **5946-47** |

Арча муниципаль районы
Иске Кырлай
авыл җирлеге башкарма комитетының
2019 елның «01» апрельдә кабул
ителгән 5 номерлы Карарына
2 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 213-97 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка предметларны китерү | 3723-46 |
| 4. Мәетне (калдыкларын) зиратка алып бару | 475-52 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1533-52 |
| **Барысы** | **5946-47** |